ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 август 2014 ел Казан шәһәре № 10-20/кс

***Эчәргә яраклы суга һәм ташландык суларны транспортлау тарифларын билгеләү турында***

“Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны транспортлау турында” 7 декабрь, 2011 ел, №416-ФЗ Федераль законга, “Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны транспортлау өлкәсендә тарифларны дәүләти җайга салу турында” 13 май, 2013 ел, № 406 Россия Федерациясе Хөкүмәте карарына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 15.06.2010 ел, № 468 карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмәгә туры китереп, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР бирә:

1. Әлеге карарның кушымтасына таянып, салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны транспортлаштырган оешмалар өчен эчәргә яраклы һәм ташландык суларны агызу тарифларын билгеләргә.
2. Бу карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2014 елның 1 гыйнварыннан 2014 елның 31 декабренә кадәр үз көчендә була.
3. Бу карарга кушымтада күрсәтелгән салкын су белән тәэмин итүне һәм ташландык суларны транспортлауны хәл итүче оешмаларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17 гыйнвар, 2013 ел, № 6 карары белән расланган мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә чираттагы җайга салу чорына тарифны билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча халыкка җиткерелергә тиешле мәгълүматны ачарга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча
Дәүләт комитеты Рәисе М.Р. Зарипов

Татарстан республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты карарына кушымта
08 август 2014 ел № 10-20/кс

Салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны
транспортлаштырган оешмалар өчен
эчәргә яраклы һәм ташландык сулар тарифлары

| № тәртип буенча | Муниципаль берәмлек, оешма, салкын су белән тәэмин итүче һәм ташландык суларны агызган оешмалар исеме | Эчәргә яраклы суга тариф (бер ставкалы), сум./куб.м | Ташландык суларны транспортлау тарифлары (бер ставкалы), сум./куб.м |
|---|---|---|---|
| | | 2014 елның 1 сентябреннән 2014 елның 31 декабренә хәтле | 2014 елның 1 сентябреннән 2014 елның 31 декабренә хәтле |
| | Югары Ослан муниципаль районы | | |
| 1 | «Волжанка» Муниципаль Унитар Оешма* | 22,97 | |
| | Алабуга муниципаль районы | | |
| 2 | «Татнефть» ААҖнең “Прикамнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсе (ӨБС исәпкә алынмаган) | 23,55 | 4,92 |

<*> оешма гадиләштерелгән салым алу системасын куллана

Татарстан Республикасы тарифлар буенча
Дәүләт комитеты, Тарифлар буенча карарларны
кабул итү, оештуры һәм җайга салу бүлеге